# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында

Әлеге Закон, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының уникаль һәм типик табигать комплексларын һәм объектларын, аларның генетик фондын, биосфераның тотрыклылыгын саклап калу, аның халәте үзгәрешен тикшереп тору, экологик мониторингны алып бару, шулай ук халыкка экологик тәрбия бирү йөзеннән, махсус сакланылучы табигать территорияләрен оештыру, саклау һәм алардан файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Әлеге Закон кысаларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

махсус сакланылучы табигать территорияләре - табигатьне саклау, фәнни, мәдәни, эстетик һәм ял итү әһәмиятенә ия булган, дәүләт хакимияте органнары карары белән хуҗалык кулланылышыннан өлешчә һәм тулысынча төшереп калдырылган һәм алар өчен саклауның махсус режимы урнаштырылган җир кишәрлекләре (аларда урнашкан табигать комплекслары һәм объектлары белән бергә), су өслеге һәм алар өстендәге һава киңлекләре ул.

махсус саклау режимы - дәүләт табигать тыюлыклары, милли парклар, дәүләт табигать заказниклары һәм табигать ядкярләре

территорияләреннән традицион хуҗалык эшчәнлегендә файдалануга, аларга кереп йөрү мөмкинлегенә, ял итүгә һәм аларда эшчәнлекнең башка төрләренә карата чикләү яисә тыю гамәлләре системасы ул, бу система алда санап үтелгән табигатьне саклау учреждениеләренең үзләренә йөкләтелгән бурычларын үтәүләрен тәэмин итә. Махсус саклау режимнары әлеге Закон һәм аның нигезендә кабул ителүче норматив-хокукый актлар тарафыннан билгеләнә;

махсус сакланылучы табигать территориясенең саклау зонасы - махсус сакланылучы табигать территориясе периметры буенча бүлеп бирелүче һәм буфер ролен үтәүче җир кишәрлеге (акватория) ул. Саклау зоналары территориясендә хуҗалык эшчәнлеге өлешчә чикләнә. Махсус сакланылучы табигать территориясенең саклау зоналары чикләре саклау зоналары турындагы тиешле нигезләмәләр тарафыннан билгеләнәләр, расланалар һәм алар натурада махсус билгеләү тамгалары белән аерылып торалар;

табигать-тыюлык фонды - табигый байлыкларны саклап калу һәм аларны торгызуны максат итеп куючы һәм аның табигый-экологик каркасын барлыкка китерүче махсус сакланылучы табигать территорияләре, сирәк очрый торган үсемлекләр һәм хайваннар җыелмасы ул;

махсус сакланылучы табигать территорияләрен оештыру - махсус сакланылучы яңа табигать территорияләрен оештыру процессы ул, аңа проект-эзләнү эшләрен уздыру, тиешле хокукый-норматив актлар кабул итү һәм хуҗалык эшчәнлеген барлыкка китерү буенча оештыру-хуҗалык гамәлләрен башкару керә;

экологик әһәмият - табигать территорияләренең һәм объектларының экологик күзлегеннән карагандагы (мохит барлыкка килүдә, биологик байлыкларны саклап калуда һәм торгызуда) зур әһәмияте ул;

ценотик фонд - үсемлек һәм хайван организмнарының уникаль һәм тарихи типик барлыкка килгән бергәлекләрнең экологик, фәнни-мәгълүмати һәм социаль-икътисадый яктан әһәмиятле җыелмасы ул.

2 статья. Махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы законнар

Махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы законнар Татарстан Республикасы Конституциясеннән, әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив-хокукый актлардан гыйбарәт була.

3 статья. Махсус сакланылучы табигать территорияләренең һәм аларны билгеләүнең категорияләре һәм рәвешләре

Хокукый статусның аермаларын, саклау режимы үзенчәлекләрен, экологик әһәмиятен исәпкә алып, махсус сакланылучы территорияләрнең түбәндәге категорияләре билгеләнә:

дәүләт табигать тыюлыклары;

милли парклар;

табигать парклары;

дәүләт табигать заказниклары;

табигать ядкярләре;

дендрологик парклар һәм ботан бакчалары;

дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар;

яшел зоналар.

Дәүләт хакимиятенең җирле органнары үз вәкаләтләре чикләрендә махсус сакланылучы табигать территорияләренең башка категорияләрен дә билгеләргә мөмкин (шәһәр урманнары, шәһәр парклары, бакча-парк сәнгате ядкярләре, елгаларның сакланылучы системасы, сакланылучы табигать ландшафтлары, биологик станцияләр, микрозаказниклар һәм башкалар).

Махсус сакланылучы табигать территорияләрен тискәре антропоген йогынтылардан яклау йөзеннән, алар тирәсенә урнашкан коры җир һәм су киңлекләре кишәрлекләрендә хуҗалык эшчәнлеге җайга салынучан саклык зоналары оештырылырга мөмкин.

Махсус сакланылучы табигать территорияләренең һәм аларның саклык зоналарының вазыйфаи җыелмасы Татарстан Республикасының махсус сакланылучы табигать территорияләренең челтәрен тәшкил итә.

Махсус сакланылучы табигать территорияләре тиешле категориядәге территорияләр составына, җир биләүче(ләр) ризалыгы белән, Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тәкъдиме буенча тиешле фәнни һәм техник-икътисадый нигезләү үткәннән соң кертелә. Җирләрне махсус сакланылучы табигать территорияләре составына кертү турындагы карарны Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты кабул итә.

Җирләрне махсус сакланылучы табигать территорияләре составына кертүгә җир биләүче(ләр) ризалык бирмәгәндә, мәсьәлә законнар нигезендә хәл ителә.

Махсус сакланылучы табигать территорияләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары , Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары карамагында, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагында булырга мөмкин.

Җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләре дәүләт хакимиятенең җирле органнары карамагында була.

Дәүләт табигать тыюлыкларының, милли паркларның, табигать паркларының һәм дәүләт табигать заказникларының территорияләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары карамагындагы, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагындагы махсус сакланылучы табигать территорияләренә кертелә. Табигать ядкярләренең, дендрология паркларының, ботан бакчаларының һәм махсус сакланылучы табигать территорияләренең башка категорияләре территорияләре республика әһәмиятендәге яисә җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләренә кертелергә мөмкин.

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагындагы махсус сакланылучы табигать территорияләре законнар нигезендә билгеләнә. Республика әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели. Җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләре әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларында урнаштырылган

тәртиптә билгеләнәләр.

4 статья. Махсус сакланылучы табигать территорияләрен үстерү һәм урнаштыру

Махсус сакланылучы бөтен табигать территорияләре һәм аларның саклык зоналары территориаль комплекслы схемаларны, җир төзелеше һәм район планлаштыру схемаларын әзерләгәндә мәҗбүри рәвештә исәпкә алынырга тиеш.

Шәһәрләр һәм районнарның социаль-икътисадый үсеше буенча перспектив планнарның гамәлләрен, территориаль комплекс схемаларының, җир эшләрен башкару схемаларының, район планлаштыруының гамәлләрен, башка гамәлләрне уздыру аркасында махсус сакланылучы табигать территорияләренә тискәре йогынты ясалу куркынычы булганда яисә аларның составы үзгәрергә мөмкин булганда, мондый гамәлләр дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсен алганнан соң гына тормышка ашырылырга тиеш. Татарстан Республикасы Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгының карары буенча кайбер гамәлләрне уздыру шушы махсус сакланылучы табигать территориясенең идарә органы белән килештерелгәннән соң гамәлгә ашырыла.

Махсус сакланылучы табигать территорияләрен һәм аларның саклык зоналарын үстерү һәм урнаштыруның кабул ителгән схемалары нигезендә махсус сакланылучы табигать территорияләре итеп игълан ителәчәк җир кишәрлекләрен резервлау турында һәм аларда хуҗалык эшчәнлеген чикләү хакында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карар кабул итә.

5 статья. Махсус сакланылучы табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм дәүләт тикшереп торуы

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары карамагындагы, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагындагы махсус сакланылучы табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм дәүләт тикшереп торуы

Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан башкарыла.

Республика әһәмиятендәге махсус саклanылучы табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм дәүләт тикшереп торуы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшчәнлеге өлкәсендә идарә һәм тикшереп тору җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарыла.

<u>6 статья.</u> Махсус сакланылучы табигать территорияләренең дәүләт кадастры

Татарстан Республикасының махсус сакланылучы табигать территорияләренең дәүләт кадастры бу территорияләрнең статусы, аларның географик урнашуы һәм чикләре, әлеге территорияләрне махсус саклау режимы, табигатьтән файдаланучылар турындагы белешмәләрдән, аларның социаль-икътисадый, фәнни-мәгълүмати , экологик-агарту, тарихи һәм мәдәни әһәмияте турындагы белешмәләрдән тора.

Махсус сакланылучы табигать территорияләренең дәүләт кадастры табигать-тыюлык фондының халәтен бәяләү,әлеге территорияләр челтәренең үсеш перспективасын ачыклау, тиешле режимны үтәүне дәүләт тарафыннан тикшереп торуның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы территорияләренең социаль-икътисадый үсешен планлаштырганда, әлеге территорияләрне исәпкә алу өчен алып барыла.

Махсус сакланылучы табигать территорияләренең дәүләт кадастры Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән бердәм схема буенча алып барыла.

Махсус сакланылучы табигать территорияләренең дәүләт кадастрын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

7 статья. Махсус сакланылучы табигать территорияләрен оештыруда, саклауда һәм аларның эшчәнлегендә гражданнарның һәм хокукый затларның катнашулары

Гражданнар һәм юридик затлар, моңа җәмәгать берләшмәләре дә керә, махсус сакланылучы табигать территорияләрен оештыру, саклау һәм эшчәнлекләрен алып бару гамәлләрен уздырганда дәүләт органнарына ярдәм күрсәтәләр. Дәүләт органнары бу гамәлләрне башкарганда гражданнарның һәм җәмәгать берләшмәләренең тәкъдимнәрен исәпкә алалар.

## П бүлек. Дәүләт табигать тыюлыклары

8 статья. Гомуми нигезләмәләр

Дәүләт табигать тыюлыклары - махсус сакланылучы табигать комплекслары һәм объектлары (җир, елга-сулар, җир куены, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы), хуҗалык кулланылышыннан тулысынча төшереп калдырыла торган территорияләр ул, бу территорияләр, табигый табигать мохите үрнәкләре буларак, табигатьне саклау, фәнни, экологик-агарту әһәмиятенә ия булалар, аларга типик яисә сирәк ландшафтлар, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының генетик фондын саклау урыннары да керә.

Дәүләт табигать тыюлыклары - табигый процессларның һәм күренешләрнең табигый агышын, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының генетик фондын, үсемлекләрнең һәм хайваннарның кайбер төрләрен һәм бергәлекләрен, уникаль экологик системаларны саклап калуны һәм өйрәнүне, экологик мониторинг алып баруны максат итеп куйган табигатьне саклау, фәнни-тикшеренү һәм экологик-агарту учреждениеләре ул.

Дәүләт табигать тыюлыклары территорияләрендә урнашкан җирләр, елга-сулар, җир куены, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы законнарда каралган тәртиптә дәүләт табигать тыюлыклары файдалануына (биләвенә)тапшырыла.

Биналар, корылмалар, тарихи-мәдәни объектлар һәм күчерелми торган башка объектлар оператив идарә итү хокукында булалар.

Дәүләт табигать тыюлыкларына кертелгән җир кишәрлекләренә һәм башка табигый байлыкларга хокукларны тартып алу яисә башкача туктату тыела.

Дәүләт табигать тыюлыкларының табигый байлыклары һәм күчерелми торган мөлкәте әйләнештән тулысынча төшереп калдырыла (башка төрле ысуллар белән тартып алынмый һәм бер заттан икенчесенә күчерелми).

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагындагы конкрет дәүләт табигать тыюлыклары турындагы нигезләмә һәм аның статусы Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт тапшырган орган һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты вәкаләт тапшырган орган тарафыннан раслана.

Республика әһәмиятендәге конкрет дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмә һәм аның статусы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

<u>9 статья.</u> Дәүләт табигать тыюлыкларының төп максатлары

Дәүләт табигать тыюлыкларына түбәндәге бурычлар йөкләнә:

тыюлык территориясен (акваториясен дә кертеп), аның генетик һәм ценотик фондын саклауны тәэмин итү;

фәнни тикшеренүләр оештыру һәм уздыру;

экологик мониторинг алып бару;

экологик белем бирү;

хуҗалык объектларын төзү һәм үзгәртеп кору проектларына дәүләт тарафыннан экологик экспертиза уздырганда катнашу.

<u>10 статья.</u> Дәүләт табигать тыюлыкларын оештыру тәртибе

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагындагы дәүләт табигать тыюлыгы әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органнары тәкъдиме буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте белән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан гамәлгә куела.

Республика әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы әйлә-

нә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органнары тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә гамәлгә куела.

Дәүләт табигать тыюлыгы территориясен киңәйтү шул ук тәртиптә башкарыла.

Аеруча кыйммәтле экологик системалар һәм объектлар (аларны саклап калу өчен дәүләт табигать тыюлыгы төзелә) кертелмәгән территорияләрдән хуҗалык итү өчен өлешчә файдалануга махсус бүлеп бирелгән кишәрлекләрдә дәүләт табигать тыюлыгының эшчәнлеген һәм шушы территориядә яшәүче гражданнарның тормыш эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек кенә рөхсәт ителә һәм әлеге табигать тыюлыгы турында расланган нигезләмә буенча гамәлгә ашырыла.

11 статья. Дәүләт табигать тыюлыкларын махсус саклау режимы

Дәүләт табигать тыюлыклары территорияләрендә (акваторияләрендә) дәүләт табигать тыюлыклары максатларына һәм шушы территорияләрне махсус саклауның әлеге дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәдә билгеләнгән режимына каршы килүче теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

җирләрнең гидрологик һәм башка табигый режимын үзгәртерлек гамәлләр;

эзләнү эшләре һәм файдалы казылмаларны эшкәртү, туфрак катламын бозу;

куак һәм агачларны төп кулланылыш һәм арадаш кулланылыш өчен кисү, нарат сагызы, агач сутларын, дару үләннәрен һәм техник чимал әзерләү;

печән чабу, көтүлекләр өчен куллану, умарталар һәм умарталыклар урнаштыру, кыргый үсемлекләрнең җимешләрен, җиләк, гөмбә, чикләвек, орлык, чәчәк җыю һәм үсемлекләр дөньясыннан башкача файдалану;

сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен һәм аларның аерым объектларын төзү һәм урнаштыру, предприятиеләр ачу, ярдәмче хуҗалыклар оештыру;

тыюлык эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле булганнардан

гайре, бүтән биналар, корылмалар, юллар һәм юлүткәргечләр, электр линияләре һәм башка коммуникацияләр төзү;

кәсби, спорт һәм һәвәскәр аучылык һәм балыкчылык, хайваннар дөньясыннан файдалануның башка төрләре;

үсемлекләрне һәм хайваннарны климатлаштыру йөзеннән интродукцияләү (читтән кертү);

үсемлекләрне яклау өчен минераль ашламалар һәм химик чаралар куллану;

терлекләрне тыюлык аша кайда да булса куу;

гомуми кулланылыштагы юллардан һәм су юлларыннан читтә чит затларның автомототранспортының урнашуы, узып китүе һәм үтеп йөрүе;

тыюлыклардагы фәнни эзләнүләр тематикасында һәм планнарында каралганнарыннан гайре, зоологик, ботаник һәм минералогик коллекцияләр җыю;

тыюлык белән яисә табигатьне саклауның тикшереп тору органнары белән килешенмичә самолетларның һәм вертолетларның коры җир яисә су киңлекләре өстеннән 2000 метрдан да түбәнрәк очып узулары;

тыюлык территорияләрендә корал белән, этләр белән, аучы кошлар белән, капканнар һәм ятмәләр белән, аучылык һәм балыкчылыкның башка кораллары белән йөрү. Аучылык һәм балыкчылык кораллары, шулай ук хокук бозучылар тоткан, кулга төшергән үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын тыюлык сакчылары тартып алалар. Тартып алынган аучылык һәм балыкчылык кораллары, хокук бозучының җаваплылык мәсьәләсе хәл ителгәнче, тыюлыкта саклана, ә хокук бозучы тоткан, кулга төшергән үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектлары билгеләнгән тәртиптә сатыла;

тыюлык режимын бозарлык, табигать процессларының табигый үсешенә тискәре йогынты ясарлык, табигать комплекслары һәм объектларының халәтенә янарлык, шулай ук тыюлыкка йөкләтелгән максатларны үтәү белән бәйләнмәгән башка төр эшчәнлек.

Дәүләт табигать тыюлыклары территорияләре (акваторияләре) чикләрендә түбәндәге гамәлләр уздырылырга мөмкин:

антропоген йогынтыны кисәтү яисә бетерү гамәлләре;

хайваннарның аеруча куркыныч массакүләм авыруларын булдырмый калу өчен кирәкле гамәлләр.

Дәүләт табигать тыюлыгы территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

хезмәткәрләргә, шулай ук пенсиягә киткәннәренә дә, аеруча әһәмиятле экологик системалардан читтә хезмәт өчен кирәкле кишәрлекләр (йорт тирәсендәге ярдәмче кишәрлекләр, печәнлекләр, көтүлек өчен кишәрлекләр) бүлеп бирелә;

аеруча әһәмиятле экологик системалардан читтә - шуның өчен махсус бүлеп бирелгән кишәрлекләрдә утын әзерләү , тыюлык максатларын, хезмәткәрләр һәм пенсионерлар ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшкә яраклы агач әзерләү;

агачларны башка төрле кисүләр (бүлеп алынучы урман мәйданнарын чистарту өчен агачларны кисү, урман кишәрлекләренең чикләрен билгеләү өчен, янгынга каршы чокырлар казу өчен һәм башка шундый максатлар өчен агачларны кисү);

әгәр элегрәк үткәрелгән мәҗбүри профилактик гамәлләр уңай нәтиҗәләргә китермәсә, җайга салу максатларында, бары тик сакланылучы зонада гына һәм законда билгеләнгән тәртиптә генә хайваннарны берәм-берәм ату (аулау);

карамакларында тыюлык булган дәүләт органнарының карары буенча гына хайваннарны берәм-берәм ату (аулау);

тыюлык хезмәткәрләре булмаган гражданнарның һәм урындагы затларның тыюлык хакимияте рөхсәте буенча тыюлык территориясендә булулары.

Дәүләт табигать тыюлыкларында "тынычлык зоналары" - кишәрлекләр бүлеп бирелә, анда кешенең табигать процессларына ничек тә булса тыкшынуы бөтенләй тыела.

<u>12 статья.</u> Дәүләт табигать тыюлыклары хокукый халәтенең үзенчәлекләре

Дәүләт табигать тыюлыклары юридик затлар булалар, алар табыш алуны үз эшчәнлекләренең максаты итеп куймыйлар, ягъни коммерция белән шөгыльләнмәүче оешмалар булалар һәм Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән финансланучы табигатьне саклау учреждениесе рәвешендә оештырылалар.

Тыюлыклар карамагында, аларның төзелмә бүлекчәләре сыйфатында, Татарстан Республикасының дәүләт табигать тыюлык фондын барлыкка китерүче махсус сакланылучы чиктәш табигать террито-

рияләре (заказниклар, табигать ядкярләре һәм башкалар) булырга мөмкин.

Дәүләт табигать тыюлыклары билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрдән керүче акчаларга хуҗа булалар:

фәнни, реклама - нәширлек эшчәнлегеннән һәм дәүләт табигать тыюлыклары максатларына каршы килмәслек башка төр эшчәнлектән;

дәүләт табигать тыюлыклары һәм аларның сакланылучы зоналары территорияләрендә урнашкан табигать комплексларына һәм объектларына китерелгән зыянны түләттерүдән;

тартып алынган аучылык, балыкчылык коралларын һәм табигатьтән законсыз файдалану продукциясен билгеләнгән тәртиптә сатудан;

бушлай ярдәм һәм иганә кертемнәре рәвешендә юридик һәм физик затлардан.

Экологик хокук бозулар өчен административ тәртиптә салынучы һәм дәүләт табигать тыюлыкларының урындагы затлары карары нигезендә түләттерелүче штрафлар дәүләт табигать тыюлыкларының мөстәкыйль карамагына күчәләр һәм аерым баланста исәпкә алыналар.

Дәүләт табигать тыюлыклары үзләренең максатларына һәм төп бурычларына каршы килерлек уртак предприятиеләрдә һәм нинди дә булса коммерция эшчәнлегендә катнашмаска, тыюлыкның җир кишәрлекләрен, башка табигать объектларын һәм бүтән мөлкәтен арендага яисә залогка тапшырмаска тиеш. Җир кишәрлекләре, торак фондын да кертеп, биналар, корылмалар хосусыйлаштырылмый.

Дәүләт табигать тыюлыклары территориясендә урнашкан хосусый торак төзелмәләре законнар нигезендә сатып алынырга яисә, искерү дәрәҗәсенә карап, сүтелергә тиеш.

Дәүләт табигать тыюлыклары үз символикасын (флаглар, вымпеллар, эмблемалар һәм башкалар) булдырырга хаклы. Дәүләт табигать тыюлыклары символикасын раслау, куллану һәм саклау тәртибе законнар нигезендә билгеләнә.

Сәнгати, басма, сувенир һәм тиражланучы башка продукцияне һәм халык куллануы товарларын дәүләт табигать тыюлыклары территориясендә урнашкан табигать һәм тарихи-мәдәни комплекслар һәм объектларның сурәтләрен, шулай ук аларның исемнәрен һәм символикасын кулланып җитештерү дәүләт табигать тыюлыклары ди-

ректорлыгының рөхсәте нигезендә генә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт табигать тыюлыкларына законнар нигезендә салым ташламалары билгеләнергә мөмкин.

## III бүлек. Милли парклар

### 13 статья. Гомуми нигезләмәләр

Милли парклар табигатьне саклау, экологик агарту һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләре булалар, аларның территорияләренә (акваторияләренә) табигатьне саклау, белем бирү-агарту, фәнни һәм мәдәни максатларда куллану өчен һәм җайга салынучан туризм өчен билгеләнгән экологик, тарихи һәм зәүкый әһәмиятле табигать комплекслары һәм объектлары керә.

Милли парклар территориясендә урнашкан җир, елга-сулар, җир куены, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы законнарда каралган хокуклар буенча милли парклар файдалануына (биләвенә) тапшырыла.

Милли парклар территорияләрендә урнашкан һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт саклавына куелган тарихи-мәдәни объектлар бары тик тарихи һәм мәдәни ядкярләрне саклауның дәүләт органнары ризалыгы буенча гына милли парклар файдалануына тапшырыла.

Кайбер очракларда милли парклар чикләрендә, башка файдаланучыларның да, шулай ук башка милекчеләрнең дә җир кишәрлекләре урнашырга мөмкин, алар милли табигать паркын саклауның билгеләнгән режимын үтәргә тиеш.

Милли парклар әлеге җирләрне Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән һәм законда тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән сатып алу хокукына бәхәссез ия булалар.

Биналар, корылмалар, тарихи-мәдәни объектлар һәм күчерелми торган башка объектлар милли паркларга оператив идарә хокукында беркетеләләр.

Конкрет милли парк әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органы ризалыгы буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланучы нигезләмәгә таянып эш итә.

Милли парк тирәсендә табигатьтән файдалануның чикләнгән режимлы саклау зонасы төзелә, аның турындагы нигезләмәне Та-

тарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый.

14 статья. Милли паркларның максатлары

Милли паркларга түбәндәге максатлар йөкләнә:

табигать комплексларын, уникаль һәм типик табигать кишәрлекләрен һәм объектларын саклау;

тарихи-мәдәни объектларны саклап калу;

халыкка экологик белем бирүне оештыру;

ял итү өчен куллану шартларында табигатьне саклауның фәнни ысулларын әзерләү һәм гамәлгә кертү;

җайга салынучан экологик туризм һәм табигать кочагында ял итү өчен шартлар тудыру;

бозылган табигый һәм тарихи-мәдәни комплексларны һәм объектларны торгызу.

15 статья. Милли паркларны оештыру тәртибе

Милли парклары оештыру турындагы, шулай ук моңа кадәр гамәлдә булган территорияләрне киңәйтү турындагы карарны дәүләт хакимиятенең җирле органнары һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органнары тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты кабул итә. Милли паркны оештыру чорында махсус сакланылучы табигать территорияләре режимы үтәлешен тикшереп торуны әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органнары башкара.

16 статья. Милли паркларны махсус саклау режимы

Милли парклар территорияләрендә (акваторияләрендә), аларның табигый, тарихи-мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, махсус саклауның дифференциацияле режимы урнаштырыла. Бу үзенчәлекләрдән чыгып, милли парклар территорияләрендә төрле вазыйфаи зоналар бүлеп куелырга мөмкин, шул исәптән:

тыюлык зонасы, аның чикләрендә теләсә нинди хуҗалык эшчәнлеге алып бару һәм территориядән рекреацион максатларда файда-

лану тыела;

катгый регламент буенча гына кереп йөрү рөхсәт ителә торган чикләрдәге табигать комплексларын һәм объектларын саклау шартларын тәэмин итүче махсус сакланылучы зона;

танып белү туризмы өчен, экологик белем бирүне оештыру һәм милли паркның истәлекле объектлары белән таныштыру өчен билгеләнгән зона;

рекреация, ял итү өчен, һәвәскәр балыкчыларга балык тоту өчен билгеләнгән зона;

мәдәни мирас комплексларын һәм объектларын саклау шартларын тәэмин итүче тарихи-мәдәни объектларны саклау зоналары;

күрергә килүчеләргә хезмәт күрсәтү зонасы, кемпинглар, чатырлы җәйләүләр һәм турист сервисының башка объектларын урнаштыру өчен, күрергә килүчеләргә мәдәни, көнкүреш һәм мәгълүмати хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән зоналар;

милли парк эшчәнлеген тәэмин итү буенча кирәкле хуҗалык һәм җитештерү эшләрен башкару өчен билгеләнгән зона.

Милли парк территорияләрендә табигать комплексларына, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына, мәдәни-тарихи объектларга зыян китерерлек һәм паркларның максатларына һәм бурычларына каршы килә торган теләсә нинди эшчәнлек, шул исәптән түбәндәгеләр тыела:

файдалы казылмаларны разведкалау һәм эшкәртү;

туфрак катламын һәм геологик өслекләрне бозуга китерә торган эшчәнлек;

су режимын үзгәртүгә китерә торган эшчәнлек;

милли парк территорияләрендә бакча һәм дача кишәрлекләре бирү;

магистраль юллар, торба үткәргечләр, электр линияләре һәм башка коммуникацияләр төзү,шулай ук милли парклар эшчәнлегенә бәйле булмаган хуҗалык, торак объектлары төзү һәм алардан файдалану;

агач әзерләү, аркылы үтеп йөрерлек юллар ясау өчен агачлар кисү, сагыз әзерләү, кыргый үсемлекләрне һәм гөмбәләрне сәнәгати әзерләү, аулау һәм балык тоту, хайваннарны һәлак итү һәм тоту;

механизацияләштерелгән транспорт чараларының хәрәкәте һәм аларның тукталышы, гомуми кулланылыштагы юллардан һәм су юлла-

рыннан читтә һәм махсус билгеләнгән урыннардан читтә йорт хайваннарын йөртү, су агымнары һәм сулыклар буйлап сал агызу;

спорт уеннарын һәм тамашаларны киң күләмдә оештыру, махсус билгеләнгән урыннардан тыш чикләрдә туристлар тукталышы булдыру һәм учаклар яндыру.

Махсус сакланылучы табигать территорияләрендәге нефть скважиналары аларның дебитларын эшкәртеп бетергәнче эш режимын саклыйлар. Нефть скважиналарының эше тәмамланганнан соң җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу, территорияләрне төзекләндерү һәм әйләнә-тирә табигать мохитен савыктыру буенча махсус сакланылучы табигать территориясе режимы нигезендә чаралар күреләә.

Тиешле милли парк территорияләрендәге һәм аларның сакланылучы зоналарындагы хуҗалык субъектларының социаль-икътисадый эшчәнлек мәсьәләләре, шулай ук шундагы торак пунктларының үсеш проектлары милли парклар белән катгый рәвештә килештереләләр.

<u>17 статья.</u> Милли паркларның хокукый халәте үзенчәлекләре

Милли парклар коммерциягә карамаган оешмалар булалар һәм Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән финансланучы табигатьне саклау учреждениесе рәвешендә төзеләләр.

Милли парклар түбәндәгеләрдән керүче акчалардан билгеләнгән тәртиптә файдаланалар:

мәдәни-агарту, рекреация, фәнни, реклама-нәширлек эшчәнлегеннән һәм милли паркларның максатларына каршы килми торган бүтән эшчәнлектән;

аренда түләүләреннән;

милли парклар территориясендә урнашкан табигый комплексларга һәм объектларга китерелгән зыянны түләттерүдән;

билгеләнгән тәртиптә конфискацияләнгән аучылык, балыкчылык коралларын һәм табигатьтән законсыз файдаланып табылган хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектлары сатудан;

юридик һәм физик затларның бушлай ярдәме һәм иганә кертемнәре рәвешендә.

Экологик хокук бозулар өчен административ тәртиптә салынучы һәм милли паркларның урындагы затлары карарлары буенча

алынучы штрафлар милли паркларның мөстәкыйль файдалануына тапшырылалар һәм алар аерым балансга исәпләнәләр.

Милли парк гамәлгә куючы була ала һәм милли паркларның үсешенә ярдәм итүче фондларның, ассоциацияләрнең һәм башка оешмаларның эшчәнлегендә катнаша ала.

Милли парклар чикләрендәге җир кишәрлекләре, шулай ук ул кишәрлекләрдә урнашкан йортлар, корылмалар, биналар хосусыйлаштырылмый.

Милли парклар үз символикасын (флаглар, вымпеллар, эмблемалар һәм башкалар) булдырырга хаклы. Милли парклар символикасын раслау, аннан файдалану һәм аны саклау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Милли парклар территориясендә урнашкан тарихи-мәдәни табигать объектларының (дини берләшмәләр милкендә булганнардан гайре), милли паркларның музей фондларындагы хәзинәләрнең сурәтләрен һәм күчермәләрен файдаланып, сәнгати, басма, сувенир продукцияләре һәм күп тиражлы башка продукцияләр һәм халык кулланылуы товарлары җитештерү милли паркларның директорлыгы рөхсәте белән башкарыла.

Милли парклар өчен законнар нигезендә ташламалы салымнар билгеләнергә мөмкин.

<u>18 статья.</u> Милли паркларга килүчеләргә хезмәт күрсәтүне оештыру

Милли парклар территорияләрендә җайга салынучан туризмны һәм ялны тәэмин итү эшчәнлеге милли паркларның директорлыклары тарафыннан бирелүче лицензияләр нигезендә расланган проектлар буенча башкарыла, килүчеләргә хезмәт күрсәтүне оештыру буенча тәкъдим ителүче гамәлләр милли парклар эшчәнлеге максатларына каршы килмәскә һәм табигый комплексларга, тарихи-мәдәни мирас объектларына зыян китермәскә тиеш. Лицензияләр бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Тиешле лицензияләре булганнарга милли паркларның директорлыклары белән төзелә торган тиешле шартнамәләрдә билгеләнгән шартларда арендага җир кишәрлекләре, табигать объектлары, биналар һәм корылмалар бирелергә мөмкин. Күрсәтелгән шартнамәләр үз карамакларында милли парклар булган дәүләт идарәсе органнарында теркәлергә тиеш.

Лицензия хуҗасы лицензия һәм аренда турында шартнамә нигезендә аның тарафыннан гамәлгә ашырылучы барлык төр эшләрнең документы проектын милли парк директорлыгы һәм үз карамагында милли парк булган дәүләт органы раславына кертә.

## 4 бүлек.Табигать парклары

### 19 статья. Гомуми нигезләмәләр

Табигать парклары - территорияләрендә (акваторияләрендә) экологик һәм зәүкый әһәмияткә ия табигать комплекслары һәм объектлары булган һәм табигатьне саклау, мәдәни-агарту, рекреация максатларында файдалану өчен билгеләнгән табигатьне саклаучы рекреация учреждениеләре алар.

Табигать парклары чикләнмәгән вакытка (даими) файдалануга тапшырылган җирләрдә урнашалар, аерым очракларда - бүтән файдаланучыларның, шулай ук милекчеләрнең җирләрендә булырга мөмкин.

Табигать паркларына түбәндәге бурычлар йөкләнә:

табигый тирәлекне, табигый ландшафтларны саклау һәм торгызу;

ял итү өчен һәм рекреация ресурсларын саклау өчен шартлар тудыру;

табигатьне саклауның нәтиҗәле ысулларын әзерләү һәм гамәлгә кертү,табигать парклырының территорияләрен рекреация максатларында файдаланганда экологик балансны саклау.

### 20 статья. Табигать паркларын оештыру тәртибе

Табигать паркларын оештыру турында, шулай ук моңа кадәр гамәлдә булганнарының территорияләрен киңәйтү турында карарны, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле җирле органнары белән килештереп, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органнары тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты кабул итә.

21 статья. Табигать паркларының хокукый халәте үзенчәлекләре

Табигать парклары - коммерциягә карамаган оешмалар булалар һәм Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән финансланучы табигатьне саклау учреждениесе рәвешендә төзеләләр.

Табигать парклары түбәндәгеләрдән керүче акчалардан билгеләнгән тәртиптә файдаланалар:

физик һәм юридик затларның эшчәнлеге аркасында китерелгән зыянны түләттерүдән;

рекреация, реклама-нәширлек эшчәнлегеннән һәм табигать паркларының максатларына каршы килми торган бүтән эшчәнлектән;

физик һәм юридик затларның, шул исәптән чит ил гражданнарының һәм халыкара оешмаларның бушлай күрсәтелүче ярдәме рәвешендә.

Табигать паркы табигать парклары үсешенә ярдәм итүче фондларның, ассоциацияләрнең һәм башка оешмаларның эшчәнлегендә законнар нигезендә катнаша ала.

22 статья. Табигать паркларының территорияләрен махсус саклау режимы

Табигать кишәрлекләренең экологик һәм рекреация әһәмиятенә бәйле рәвештә табигать парклары территорияләрендә махсус саклауның һәм файдалануның төрле режимы билгеләнә. Шуннан чыгып, табигать паркларының территорияләрендә табигатьне саклау, рекреация, агрохуҗалык зоналары һәм бүтән юнәлештәге зоналар бүленеп алынырга мөмкин, тарихи-мәдәни комплексларны һәм объектларны саклау зоналары да шунда керә.

Табигать паркларының чикләрендә аларның территорияләренең экологик, мәдәни һәм рекреация әһәмиятен киметерлек эшчәнлек төрләрен башкару тыелырга яисә чикләнергә мөмкин.

Табигать парклары территорияләрендә һәм аларның саклану зоналарында урнашкан юридик затларның социаль-икътисадый эшчәнлеге мәсьәләләре, шулай ук торак пунктларын үстерү проектлары табигать парклары белән килештереләләр.

Һәр табигать паркының конкрет үзенчәлекләре, аларны зона-

ларга бүлү һәм аларның эшләү режимы, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле җирле органнары белән килештереп, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланучы шушы табигать паркы турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

## У бүлек. Дәүләт табигать заказниклары

### <u>23 статья.</u> Гомуми нигезләмәләр

Дәүләт табигать заказниклары - табигать комплексларын яисә аларның компонентларын саклау яки торгызу өчен һәм экологик балансны саклау өчен аеруча әһәмияте булган территорияләр (акваторияләр) алар.

Файдаланучылардан, биләүчеләрдән һәм милекчеләрдән җир кишәрлекләрен аерып алып та, аерып алмыйча да, территорияне дәүләт табигать заказнигы дип игълан итәргә мөмкин.

Дәүләт табигать заказниклары төрле юнәлештә булырга мөмкин, шул исәптән түбәндәге табигать заказниклары да була ала:

табигать комплексларын (табигать ландшафтларын) саклау һәм торгызу өчен билгеләнгән комплекслы (ландшафтлы);

үсемлекләр һәм хайваннарның сирәк очрый һәм бетеп бара торган төрләрен,шул исәптән хуҗалык ягыннан, фәнни һәм мәдәни яктан әһәмиятле төрләрен саклау һәм торгызу өчен билгеләнгән биологик (ботаник һәм зоологик);

казылма объектларны саклау өчен билгеләнгән палеонтологик;

әһәмиятле су объектларын һәм экологик системаларны саклау һәм торгызу өчен билгеләнгән гидрологик (саз, күл, елга);

терек булмаган табигатьнең әһәмиятле объектларын һәм комплексларын саклау өчен билгеләнгән геологик.

Дәүләт табигать заказниклары әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органнары карамагында була һәм Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән һәм закон тарафыннан тыелмаган башка чыганаклардан финанслана.

Дәүләт табигать заказникларының эшчәнлеген тәэмин итү

өчен аларның администрацияләре төзелә.

Дәүләт табигать заказниклары өчен законнар нигезендә ташламалы салымнар билгеләнергә мөмкин.

24 статья. Дәүләт табигать заказникларын төзү тәртибе

Дәүләт табигать заказниклары, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле җирле органнары белән килештереп, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән гамәлгә куела.

25 статья. Дәүләт табигать заказниклары территорияләрен махсус саклау режимы

Дәүләт табигать заказниклары территорияләрендә (акваторияләрендә) аларны төзү максатларына каршы килә торган яисә табигать комплексларына һәм аларның компонентларына зыян китерә торган теләсә нинди эшчәнлек бөтенләйгә яисә вакытлыча тыела йә чикләнә.

Конкрет дәүләт табигать заказнигы территориясен махсус саклау режимының бурычлары һәм үзенчәлекләре, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле җирле органнары белән килештереп, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан расланучы әлеге табигать заказнигы турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

Дәүләт табигать заказниклары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, аларны биләүчеләр һәм алардан файдаланучылар дәүләт табигать заказникларында билгеләнгән махсус саклау режимын үтәргә тиешләр һәм аны бозган очракта законнар нигезендә җаваплы булалар.

## VI бүлек. Табигать ядкярләре

### 26 статья. Гомуми нигезләмәләр

Табигать ядкярләре - экологик, фәнни, мәдәни һәм зәвкый яктан уникаль, алыштыргысыз, аеруча әһәмиятле табигать комплекслары, шулай ук табигый һәм ясалма юл белән барлыкка килгән объектлар алар.

Республика әһәмиятенә ия яисә җирле әһәмияткә ия табигать ядкярләре булырга мөмкин.

### 27 статья. Табигать ядкярләре булган территорияләрне махсус сакланылучы табигать территорияләре дип тану тәртибе

Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан табигать объектлары һәм комплекслары - республика әһәмиятенә ия табигать ядкярләре дип, ә алар биләп торган территорияләр республика әһәмиятенә ия махсус сакланылучы табигать территорияләре дип игълан ителә.

Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органы белән килештереп, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле җирле органнары тарафыннан табигать объектлары һәм комплекслары - җирле әһәмияткә ия табигать ядкярләре дип, ә алар биләп торган территорияләр җирле әһәмияткә ия махсус сакланылучы табигать территорияләре дип игълан ителә.

Махсус сакланылучы табигать территорияләрен төзү турында карар кабул иткән дәүләт хакимияте органнары үз карамакларындагы табигать ядкярләре территорияләренең чикләрен раслыйлар һәм аларны махсус саклау режимын билгелиләр. Табигать ядкярләрен һәм аларның территорияләрен үз карамакларындагы затларга саклау өчен тапшыру, саклау йөкләмәләрен, паспорт һәм башка документларны тутыру әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Табигать ядкярләре биләгән җир кишәрлекләре милекчеләреннән, аларны биләүчеләрдән һәм алардан файдаланучылардан әлеге кишәрлекләрне аерып алып, андагы табигать комплексларын һәм объектларын - табигать ядкярләре дип, ә алар биләп торган территорияләрне махсус сакланылучы табигать территорияләре дип игълан итү рөхсәт ителә.

Республика ихтыяҗлары өчен файдаланылучы җир кишәрлекләрен яисә су киңлекләрен аерып алу кирәк булганда, табигать комплексларын һәм объектларын табигать ядкярләре дип игълан итү Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Табигать ядкярләре биләп торган территорияләр тирәсендә, хуҗалык эшчәнлегенең кайбер төрләре чикләнеп, саклау зоналары төзелергә мөмкин.

28 статья. Табигать ядкярләре территорияләрен махсус саклау режимы

Табигать ядкярләре урнашкан территорияләрдә һәм аларның сакланылучы зоналары чикләрендә табигать ядкярләренең саклanышын боза торган теләсә нинди эшчәнлек алып бару тыела.

Табигать ядкярләре булган җир кишәрлекләре милекчеләре, аларны биләүчеләр һәм алардан файдаланучылар табигать ядкярләрен махсус саклау режимын үтәү буенча үзләренә йөкләмәләр алалар.

Күрсәтелгән җир кишәрлекләре милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең һәм алардан файдаланучыларның табигать ядкярләрен махсус саклау буенча билгеләнгән режимын тәэмин итү чыгымнары Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджет акчалары исәбеннән, шулай ук бюджеттан тыш фондларның акчалары исәбеннән түләнә.

## VII бүлек. Дендрология парклары һәм ботан бакчалары

29 статья. Гомуми нигезләмәләр

Дендрология парклары һәм ботан бакчалары - үсемлекләр

дөньясының төрлелеген саклау һәм аны баету максатларында үсемлекләрнең махсус коллекцияләрен төзү, шулай ук фәнни, укыту һәм мәдәни-агарту эшчәнлеген гамәлгә ашыру бурычларын үз өстенә алган табигатьне саклау учреждениеләре алар.

Дендрология парклары һәм ботан бакчалары үзләренең турыдан-туры бурычларын үтәү өчен генә билгеләнәләр, бу чакта җир кишәрлекләре дендрология паркларына, ботан бакчаларына, шулай ук үз карамакларында дендрология парклары һәм ботан бакчалары булган фәнни-тикшеренү яисә белем бирү учреждениеләренә чикләнмәгән вакытка (даими) тапшырыла.

Дендрология паркларының һәм ботан бакчаларының балансында булган биналар, корылмалар һәм йортлар хосусыйлаштырылмый.

Республика әһәмиятенә ия һәм җирле әһәмияткә ия дендрология парклары һәм ботан бакчалары булырга мөмкин, республика әһәмиятенә ия булганнары әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән төзелә, ә җирле әһәмияткә ия булганнары, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органнары белән килештереп, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле җирле органнары тарафыннан төзелә.

## 30 статья. Дендрология паркларын һәм ботан бакчаларын махсус саклау режимы

Дендрология парклары һәм ботан бакчалары территорияләрендә аларның максатларын үтәүгә бәйле булмаган һәм флора объектларының сакланышын бозуга китерә торган теләсә нинди эшчәнлек тыела.

Дендрология парклары һәм ботан бакчалары территорияләре төрле юнәлештәге зоналарга бүленергә мөмкин, шул исәптән:

экспозицион юнәлештәге, аңа кереп йөрү дендрология парклары һәм ботан бакчалары директорлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә генә рөхсәт ителә;

фәнни-эксперименталь, аңа бары тик дендрология паркларының яисә ботан бакчаларының фәнни хезмәткәрләре, шулай ук бүтән фәнни-тикшеренү учреждениеләренең белгечләре генә кереп йөри

ала;

административ.

һәр дендрология паркының һәм ботан бакчасының конкрет максатлары, фәнни юнәлеше, хокукый халәтенең үзенчәлекләре, оештырылышы бу учреждениеләрне төзү турында карар кабул итүче дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле җирле органнары тарафыннан раслана торган алар хакындагы нигезләмәләрдә билгеләнә.

31 статья. Дендрология паркларын һәм ботан бакчаларын финанслау

Дендрология парклары һәм ботан бакчалары республика бюджеты яисә җирле бюджетлар исәбеннән һәм законда тыелмаган башка чыганаклардан финанслана.

Дендрология парклары түбәндәгеләрдән керүче акчалардан билгеләнгән тәртиптә файдаланалар:

физик һәм юридик затларның эшчәнлеге аркасында китерелгән зыянны түләттерүдән;

рекреация, реклама-нәширлек эшчәнлегеннән һәм дендрология парклары һәм ботан бакчалары максатларына каршы килми торган бүтән эшчәнлектән;

физик һәм юридик затларның, шул исәптән чит ил гражданнарының һәм халыкара оешмаларның бушлай ярдәме рәвешендә.

Дендрология парклары һәм ботан бакчалары өчен законнар нигезендә ташламалы салымнар билгеләнергә мөмкин.

## VIII бүлек. Дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар

32 статья. Гомуми нигезләмәләр

Авыруларны дәвалауны һәм профилактикалауны оештыру өчен яраклы, шулай ук табигать дәвалау ресурсларына (шифалы суларга, дәвалау ләмнәренә, башка табигый объектларга һәм шартларга) ия территорияләр (акваторияләр) дәвалау-сәламәтләндерү урыннарына кертелергә мөмкин.

Дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар алардан нәтиҗәле файдалану һәм аларның табигый ресурсларын һәм сәламәт-

ләндерү үзлекләрен саклауны тәэмин итү максатларында бүлеп бирелә.

Дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар федераль, республика яисә җирле әһәмияткә ия булырга мөмкин.

Территорияләрне дәвалау-сәламәтләндерү урыннарына һәм курортларга кертү законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

33 статья. Дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны саклауның махсус режимы

Дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар чикләрендә дәвалау үзлекләренә ия табигать ресурсларының һәм объектларының сыйфатын начарайтуга һәм аларның кимүенә китерүче хуҗалык эшчәнлеге алып бару тыела (чикләнә).

Халыктагы авыруларны дәвалауны һәм профилактикалауны оештыру өчен уңай табигать факторларын саклау максатларында, дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курорт территорияләрендә санитар саклау яисә тау санитар саклау тирәлеге оештырыла.

Дәвалау ресурслары җир куены байлыкларына (шифалы суларга, дәвалау ләмнәренә һәм башкаларга) кертелүче дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар өчен тау санитар саклау тирәлекләре билгеләнә. Калган очракларда санитар саклау тирәлекләре билгеләнә. Санитар саклау (тау санитар саклау) тирәлегенең тышкы контуры дәвалау-сәламәтләндерү урыны яисә курорт чиге була.

Санитар саклау һәм тау санитар саклау тирәлекләрен оештыру тәртибе һәм аларның эшчәнлек режимының үзенчәлекләре законнар нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## IX бүлек. Яшел зоналар

34 статья. Яшел зоналарны оештыру һәм саклау тәртибе

Мохитне саклау, санитар-гигиена һәм рекреация вазыйфаларын үтәүче территорияләр буларак, шәһәрләр, башка торак пунктлары тирәсендә һәм яшел зоналар, шул исәптән урман-парк саклау пояслары бүленә.

Халык сәламәтлеге өчен аеруча әһәмияткә ия яшел зоналар дәүләт идарәсенең тиешле җирле органнары тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән махсус сакланылучы табигать территорияләренә кертелергә мөмкин.

Яшел зоналарда аларның экологик, санитар-гигиена, рекреация вазыйфаларын башкаруга тискәре йогынты ясарлык хуҗалык эшчәнлеге алып бару тыела.

## X бүлек. Махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклауны оештыру

### 35 статья. Дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар территорияләрендәге табигать комплексларын һәм объектларын саклау

Дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар территорияләрендәге табигать комплексларын һәм объектларын саклауны хезмәткәрләре табигатьне саклау буенча тиешле учреждениеләр штатына керүче дәүләт табигать тыюлыкларын һәм милли парекларны саклау буенча махсус дәүләт инспекциясе гамәлгә ашыра.

Дәүләт табигать тыюлыкларының һәм милли паркларның директорлары һәм аларның урынбасарлары шушы дәүләт табигать тыюлыкларын һәм милли паркларны саклау буенча баш дәүләт инспекторлары һәм аларның урынбасарлары булалар.

### 36 статья. Табигать паркларының, дәүләт табигать заказникларының территорияләрен һәм махсус сакланылучы бүтән табигать территорияләрен саклау

Табигать паркларының, дәүләт табигать заказникларының территорияләрен һәм махсус сакланылучы бүтән табигать территорияләрен саклауны үз карамакларында шушы территорияләр булган дәүләт органнары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

Республика әһәмиятенә ия дәүләт табигать заказниклары территорияләрен саклаучы хезмәткәрләр дәүләт табигать тыюлыкларын һәм милли паркларны саклау буенча дәүләт инспекторлары хокукларыннан файдаланалар.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары җирле әһәмияткә ия махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау чараларын шушы максат өчен махсус төзелгән һәм тиешле вәкаләтләр тапшырылган структур бүлекчәләр аша гамәлгә ашыралар.

## XI бүлек. Махсус сакланылучы табигать территорияләре өлкәсендә халыкара шартнамәләр

### 37 статья. Махсус сакланылучы табигать территорияләре өлкәсендә халыкара шартнамәләр

Әгәр махсус сакланылучы табигать территорияләре өлкәсендә Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә әлеге Законындагыдан бүтәнрәк кагыйдәләр билгеләнсә, ул чакта халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

## XII бүлек. Йомгак нигезләмәләр

### 38 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

3 sak-masa.txt

Казан шәһәре,
1997 елның 16 октябре
№ 1360